УДК 28:94(470.41) (=512.145)

***Ә.Т. Сибгатуллина***

# ГАЛИМҖАН БАРУДИ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ ТӨРЕКЧӘ ДӨНЬЯ КҮРДЕ

*Bolşevik Rejimde Bir Tatar Şeyhülislâmı: Alimcan Barudi'nin Hatıraları (1920–1921)*. Tatarca yazma aslından Türkiye Türkçesi'ne aktaran Ömer Hakan Özalp. Istanbul: İşaret Yayınları, 2024. 717 s.

Статья посвящена анализу изданной на турецком языке книги «Татарский шейхульислам в большевистском режиме: мемуары Галимджана Баруди (1920–1921)», представляющей собой публикацию и перевод дневников муфтия Галимджана Баруди (1857–1921). Перевод рукописей текстов осуществлен Омером Хаканом Озалпом (1964 г. р.) – независимым исследователем, известным своими трудами, посвященными Ризе Фахретдинову, Нургали Хасанову и другим представителям татарской религиозной мысли. В статье отмечаются структурная целостность издания, тщательная текстологическая подготовка, наличие развернутого научного аппарата (примечаний, индекса), а также глубокое владение составителем историческим и филологическим материалом. Делается вывод о высокой источниковедческой ценности мемуаров, сочетающих личное свидетельство, богословский анализ и наблюдения за социально-политическими процессами начала XX века.

**Ключевые слова:** Галимджан Баруди, мусульмане России, татарская религиозная мысль, большевистский режим, джадидизм

The article analyzes the Turkish-language edition of the book "A Tatar Shaykh al Islam under the Bolshevik Regime: The Memoirs of Galimjan Barudi (1920–1921)", which presents a publication and translation of the diaries of Mufti Galimjan Barudi (1857–1921). The translation of the manuscript texts was carried out by Ömer Hakan Özalp, a scholar known for his studies on Riza Fakhretdinov, Nurgali Khasanov, and other representatives of Tatar religious thought. The article highlights the structural coherence of the edition, its careful textual preparation, the presence of a comprehensive scholarly apparatus (including notes and an index), as well as the editor's strong command of historical and philological material. It concludes that the memoirs possess significant source value, combining personal testimony, theological analysis, and observations on the socio-political processes of the early XX century.

**Keywords:** Galimjan Barudi, Muslims of Russia, Tatar religious thought, Bolshevik regime, Jadidism

Төркия галимнәре Казан татарларының тарихы, әдәбияты, дини-интеллектуаль мирасы һәм иҗтимагый фикере белән бәйле җитди фәнни хезмәтләр әзерләү һәм бастыру эшен эзлекле рәвештә дәвам итәләр. Соңгы елларда дөнья күргән басмалар моның ачык дәлиле булып тора. Шуларның берсе – күренекле дин әһеле Галимҗан Барудиның (1857–1921) шәхесе һәм эшчәнлегенә багышланган зур күләмле фундаменталь хезмәт: Өмәр Хакан Өзалп тарафыннан әзерләнгән

«Большевик режимында бер татар шәйхелисламы: Галимҗан Барудиның хатирәләре (1920–1921)» исемле китап. Өмәр Хакан Өзалпның татар дини-фикри тарихына кагылышлы аналитик һәм текстологик хезмәтләре моның белән генә чикләнми. Аның эшчәнлеге киң тематик колачка ия. Мәсәлән, Риза Фәхреддиннең (1859–1936) иҗтимагый фикерен анализлауга багышланган «Казан белән Истанбул арасында бер галим: Ризаэддин бине Фәхреддин» (2001)[1] исемле хезмәте татар яңарыш чорындагы интеллектуаль процессларны Госманлы дәүләте киңлеге белән бәйләп карый. Ул шулай ук «Ризаэддин бине Фәхреддин. Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр» (Истанбул, 2007) исемле җыентыкта татар галименең ислам дине һәм җәмгатьчелеккә кагылышлы хезмәтләрен туплап, фәнни эшкәртеп нәшер итте. Йосыф Акчуранын (1876–1935) 1913 елда ясаган Сүрия – Палестина – Иерусалим сәяхәте белән бәйле хатларын һәм сионизм турындагы фикерләрен татар теленнән тәрҗемә итеп бастырды[2]. Өмәр Хакан Өзалп әфәнде тарафыннан әзерләнгән «Солтан Габделхәмид сараенда бер татар мөдәррисенең Истанбул, Бурса һәм сүррә алае белән бәйле хаҗ хатирәләре (1906–1907): Нургали бин Хәсән» (2021)[3] исемле хезмәттә исә Буа имамы Нургали Хәсәновның (1810–1882) гарәп телендә сакланып калган язма тексты төрекчәгә тәрҗемәдә бирелгән. Бу өр-яңа чыганак фәнни җәмгатьчелек өчен тагын бер тарихи шәхесебезне табып зурларга ярдәм итте. Өмәр Хакан Өзалп әфәнденең бу хезмәтләре тиешле аңлатмалар һәм тарихи шәрехләр, төпле кереш сүз белән баетылган, һәм, һичшиксез, татар дин әһелләренең госманлы-төрек дөньясы белән бәйләнешләрен документаль нигездә өйрәнү мөмкинлеге бирә.

Мөфти Галимҗан Барудига багышланган хезмәтенең ни өчен «Большевик режимында бер татар шәйхелисламы» дип аталуын Өмәр Хакан әфәнде болай дип аңлата: Россиядәге Диния нәзарәте Госманлы дәүләтендәге «Баб-ы Мәшиһәт» оешмасына тиң, ә аның җитәкчесе мөфти, функцияләре ягыннан Төркиядәге шәйхелислам дәрәҗәсенә туры килә. Госманлы системасында мөфтиләр исә шәйхелислам карамагында эшләүче төбәк дин әһелләре булып саналган. Шул рәвешле, автор Россия мөфтие статусын тарихи аналогия аша шәйхелислам дәрәҗәсе белән тиңли, ягъни төрекчә китапның исемендә Баруди хәзрәтләре мөфти буларак кына күрсәтелсә, бүгенге укучылар өчен аның дини статусы күпкә түбәнрәк булып аңлашылыр иде. Әлеге китапта Барудиның дин, мәгърифәтчелек һәм идарә өлкәсендәге роле киң контекстта карала, аның мирасы тарихи чыганаклар

[1] *Ömer Hakan Özalp.* Rızaeddin bin Fahreddin: Kazan'la Istanbul Arasında Bir Alim, Dergah Yayınları, Istanbul, 2001; Rızaeddin bin Fahreddin. *Dini ve İctimai Meseleler.* Derleyen: Ömer Hakan Özalp. İstanbul, Özgü yay. 2007.

[2] Mektuplarla Suriye-Filistin-Kudüs Seyahati ve Siyonizm Meselesi. Tatarçadan haz. Ömer Hakan Özalp. İstanbul, İşaret yay.2019. 416 s.

[3] Sultan Abdülhamid'in Sarayında: Bir Tatar Müderrisin İstanbul, Bursa ve Surre Alayı le Hac Hatıraları / Nurali bin Hasan. Arapçadan tercüme: Ömer Hakan Özalp. İstanbul: İşaret yay., 2021.

нигезендә комплекслы анализлана. Бу басма Төркиядә татар дини-фикри традициясенә карата тотрыклы фәнни кызыксыну булуын тагын бер кат раслый.

Галимҗан Барудиның 1917 елдан алып вафатына кадәр (1921) язылган хатирәләре безнең көннәргә өч төп кулъязма җыентык рәвешендә килеп җиткән. Аларның күпчелек өлеше үз вакытында Шәһәр Шәрәф (1877–1938) тарафыннан күчереп язылган һәм галимнәр Энгель Нигъмәтуллин[1], Мәсгуд Гайнетдинов[2], Айдар Гайнетдинов һәм Руслан Хәбибуллин[3] текстларны кирилл хәрефләренә күчереп, төрле басма версияләр аша фәнни әйләнешкә керткәннәр иде инде. Өмер Хакан Өзалп, әлбәттә, бу чыганаклар белән таныш булса да, үз хезмәтендә КФУның Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә саклана торган, Шәһәр Шәрәф тарафыннан кайбер искәрмәләр һәм төзәтмәләр белән күчерелгән кулъязма нөсхәләр белән эш иткән, хатирәләрнең 1920–1921 елларны колачлаган II һәм III дәфтәрләрне, шулай ук өзек хәлдә калган IV дәфтәрне[4] төрек теленә тәрҗемә иткән. Шулай итеп, Өмәр Хакан әфәнде, текстның оригиналы белән эшләп, үз хезмәтенең фәнни яктан нигезле һәм төпле булуын тәэмин иткән. Нәтиҗәдә, укучыга революциядән соңгы катлаулы чорда татар мөселман руханиларының фикер дөньясын, үзбилгеләнү өчен көрәшен һәм сәяси шартларга мөнәсәбәтен әчке яктан күрсәтүче кыйммәтле текст тәкъдим ителә.

Басманың текстологик концепциясе оригиналга тугрылык принцибына нигезләнгән. Әсәр «Беренче җилд», «Икенче җилд» һәм «Өченче җилд» рәвешендә өч төп бүлеккә бүленгән, бу композицион төгәллек кулъязманың эчке структурасын сакларга мөмкинлек бирә. Барудиның 1917–1918 елларга караган Бохара һәм Себер сәфәрләре материаллары, төп хронологик бөтенлекне бозмас өчен, «Кушымталар» бүлегендә аерым урнаштырылган. Мондый карар текстның логик агышын тәэмин итә һәм игътибар үзәгендә торган төп чор – 1920–1921 еллар контекстыннан читкә чыгармый.

---

[1] Баруди нәселе дәвамчысы профессор Булат Галиев үзендә сакланган кулъязма текстны Э. Нигъмәтуллинга рус теленә тәрҗемә иттерә, һәм текст «Казань» журналының 1997 (№ 10–12), 1998 (№ 1–2) елгы саннарында басыла. Соңыннан 2000 елда «Иман» нәшриятында аерым китап булып дөнья күрә: Галимджан хазрат Баруди. Памятная книжка (Хәтер дәфтәре). Казань: Иман, 2000. 147 с.

[2] *Әл-Баруди Г.* Хатирә дәфтәре. Казан: Иман, 2007. 137 б.

[3] *Баруди Г.* Хатирә дәфтәре: 1920 елның 12 июненнән алып сентябрь ахырына кадәр / басмага әзерл. А. Гайнетдинов. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2017. 236 б.; *Баруди Г.* Хатирә дәфтәре: 1920 елның октябреннән алып 1921 елның ноябренә кадәр / басмага әзерл.: А. Гайнетдинов, Р. Хәбибуллин. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2018. 272 б.

[4] Беренче дәфтәр Барудиның Төркестан һәм Казахстанга сәяхәтенә багышланган булып, 1917–1919 елларны үз эченә ала. М. Гайнетдинов 2004 елда бу дәфтәрне «Иман» нәшриятында «Кызылъяр сәфәре» исеме белән бастырып чыгара. Хронологик яктан Өмәр Хакан Өзалпның тикшеренү чорына туры килмәгәнлектән, ул бу дәфтәргә аерым тукталмый.

Өмәр Хакан Өзалп тарафыннан текстны археографик яктан эшкәртү дә җентекле башкарылган. Кайбер татарча мәкальләр һәм фразеологик әйтелмәләр оригинал формасында сакланган, кайберләренең төрекчә варианты табылган; гарәп һәм фарсыча урыннар тәрҗемә ителгән, кыска гыйбарәләрнең укылышы бирелгән. Текстка кертелгән өстәмәләр һәм аңлатмалар аерым күрсәтелгән, болар барысы да фәнни җаваплылык таләпләренә туры килә. Китапта искәрмәләр, фотоматериаллар, абзац башлыклары бирү урынлы кулланылган. «Тәкъдим» өлешендә Барудиның тормыш юлы артык киңәйтелмичә генә бирелгән, ә тулы биографиясе соңыннан аерым урнаштырылган. Галимнең Шәрәфләр гаиләсе хакында биргән җентекле мәгълүматы да үзенең киңлеге һәм тулылыгы белән сокландыра.

Гомумән, әлеге басма текстологик яктан төгәл, археографик яктан нигезле һәм фәнни стандартларга җавап бирә. Ул мемуар жанры кысаларында гына калмыйча, сәяси-теологик документ, дини фикер тарихы буенча чыганак һәм совет чорында ислам институтларының трансформациясен күрсәткән комплекслы материал буларак әһәмият казана. Галимҗан Барудиның үз дәвере вакыйгаларына карата субъектив позициясе текстның табигый үзенчәлеге булып тора, ләкин бу субъективлык тарихи материалның кыйммәтен киметми, киресенчә, чор атмосферасын җанлы рәвештә тоярга мөмкинлек бирә. Шуңа күрә хезмәт XX гасыр башындагы татар һәм гомумрусия мөселман җәмгыятенең интеллектуаль һәм институциональ тарихын өйрәнүдә мөһим урын биләр дип ышанырга кирәк.

Баруди тексты – гади сәфәр көндәлеге яки шәхси истәлекләр җыентыгы гына түгел, ә 1920–1921 еллардагы Русия мөселман җәмгыятенең сәяси, дини һәм социаль халәтен чагылдырган комплекслы интеллектуаль документ. Баруди үз язмаларын «рузнамә» дип атый, әмма алар фактик хроникадан тыш, тирән фикерләү, бәяләү һәм анализ элементлары белән баетылган. Шуңа күрә әсәр мемуар, сәяси хроника һәм дини-фәлсәфи трактат сыйфатларын берләштерә.

Әсәрнең беренче зур тематик катламы Русия мөселманнарының Төркия белән мөнәсәбәтләренә багышлана. Баруди хилафәт мәсьәләсен үзәк проблемаларның берсе итеп куя, Беренче бөтендөнья сугышыннан соң Госманлы дәүләтенең таркалуын, солтан Вәхдеддиннең легитимлыгын, Әнкара һәм Истанбул хөкүмәтләре арасындагы каршылыкларны бәяли. Мостафа Кәмал җитәкчелегендәге милли хәрәкәт һәм аның Русия белән мөнәсәбәтләре дә игътибар үзәгендә тора. Автор өчен төп сорау – ислам дөньясы сәяси таркалу шартларында рухи бердәмлекне саклау мөмкинме? Ул гомумислам бердәмлеге (панисламизм) идеясен үзенең рухи һәм сәяси карашларының нигезе итеп кабул итә, әмма шул ук вакытта сәяси реализм позициясен тота: тарихи шартларны исәпкә алмыйча, хисләргә генә таянган бәя бирүдән саклана. Русия мөселманнарының Төркиягә каршы сугышырга теләмәве, дин кардәшлеге хисе, Төркиядәге вакыйгаларга игътибар белән карау – болар барысы да әсәрдә җентекле тасвирлана.

Бу өлеш XX гасыр башындагы мөселман дөньясының халыкара сәяси карашларын аңлау өчен мөһим чыганак булып тора.

Икенче зур тематик юнәлеш Русия мөселманнарының эчке дини, сәяси һәм иҗтимагый проблемаларына багышланган. Әсәрнең иң күләмле һәм тирән эчтәлекле бу өлешендә Коръән тәрҗемәсе, ана телендә гыйбадәт кылу, гыйльми тәфсир, мәзһәбләр мәсьәләсе, кадимчелек белән җәдитчелек арасындагы каршылыклар кебек теологик проблемалар күтәрелә. Баруди традиция белән яңарыш арасында баланс эзли; ул исламны чор шартларына яраклаштыру кирәклеген таный, әмма нигез принциплардан баш тартуны кабул итми, динне абстракт догматика түгел, ә тормышның практик системасы итеп карый. Поездда һәм пароходта намаз уку, озын көннәрдә ясту һәм тәравих намазлары, корбан чалу, мәүлид уздыру, мөселманча ай башын билгеләү кебек практик мәсьәләләр автор тарафыннан реаль тормыш шартларында анализлана. Шулай ук хатын-кызларның мәчеткә йөрү-йөрмәве, җәмгыятьтәге роле, белем алу хокукы кебек темалар да күтәрелә, бу авторның иҗтимагый мәсьәләләргә битараф булмавын дәлилли.

Баруди истәлекләрендә мәгариф темасы аерым урын били. Совет мәктәпләренең балаларга йогынтысы, балаларның руслашу куркынычы, мәдрәсәләрнең хәле, дини белем бирүне чикләү кебек мәсьәләләр авторны аеруча борчый. Ул милли һәм дини үзенчәлекне саклау проблемасын күтәрә, ислам мәгариф системасының реформасын кирәк дип саный. Бу яктан әсәр татар җәмгыятенең мәдәни үзгәрешен өйрәнү өчен кыйммәтле чыганак булып тора.

Өченче тематик катлам Диния нәзарәте белән большевиклар хакимияте арасындагы мөнәсәбәтләргә карый. Бу өлештә административ басым, цензура, биналарны һәм архивларны тартып алу, дин укытуны тыю, руханиларны мәҗбүри хезмәткә алу, мәхәлләләргә контроль урнаштыру кебек күренешләр тасвирлана. Аеруча «кызыл муллалар» феномены һәм мөселман җәмгыятен бүлү омтылышы автор тарафыннан тәнкыйди бәяләнә. Совет дәүләтенең ислам институтларын контрольгә алу стратегиясе, дини вәкаләтләрне дәүләт структураларына күчерү, никах һәм мирас кебек мәсьәләләрдә шәригатьне читкә этү омтылышы текстта конкрет мисаллар аша күрсәтелә.

Ислам белән коммунизм арасындагы мөнәсәбәт мәсьәләсе әсәрдә киң урын ала. Баруди социаль тигезлек һәм гаделлек идеяләренең исламда да булуын таный, ләкин коммунизмның дини-онтологик нигезләре ислам белән туры килмәвен ассызыклый. Аның фикеренчә, исламны сәяси идеологиягә буйсындыру рухи бәйсезлекне югалтуга китерә. Шулай итеп, әсәрдә ислам һәм социализм арасындагы мөнәсәбәт гади «каршылык» схемасы белән генә түгел, ә катлаулы интеллектуаль дискуссия рәвешендә бирелә.

Шуның белән бергә, текстта этнографик һәм социологик әһәмияткә ия материал да күп. Авылларның демографиясе, икътисади хәл, ачлык, кыйммәтчелек, авыл хуҗалыгы, көнкүреш традицияләре, ризык, кием, гигиена һәм дәвалау ысуллары турында мәгълүматлар

урын алган. Танылган дин әһелләре, галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре турында биографик белешмәләр дә әсәрнең кыйммәтен арттыра. Бу яктан истәлекләр татар дини интеллигенциясенең коллектив портретын формалаштыручы чыганак булып тора.

Гомумән алганда, әсәрнең тематик структурасы ислам, милләт һәм дәүләт арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне күрсәтә. Барудиның язмалары шәхси истәлекләр чикләрен узып, кризис чорындагы дини фикернең, институциональ көрәшнең һәм рухи җаваплылыкның тере документын тәшкил итә. Шуңа күрә бу текст XX гасыр башындагы татар һәм Русия мөселман җәмгыятенең интеллектуаль тарихын өйрәнүдә зур әһәмияткә ия.

Әсәрнең фәнни кыйммәте, беренче чиратта, аның беренчел чыганак буларак әһәмияте белән билгеләнә. Галимҗан Баруди вакыйгаларның турыдан-туры шаһиты һәм катнашучысы буларак яза, шуңа күрә текст татар тарихы өчен документаль база вазифасын үти. Диния нәзарәтенең эш механизмы, карарлар кабул итү процессы, дәүләт органнары белән рәсми һәм рәсми булмаган аралашу формалары – болар барысы да эчке яктан күрсәтелә. Бу материал XX гасыр башында Русия мөселманнарының идарә системасын реконструкцияләү өчен уникаль мәгълүмат бирә.

Йомгаклап әйткәндә, Барудиның язмалары фәнни яктан югары кыйммәткә ия: ул дини институтлар тарихы, ислам хокукының трансформациясе, татар җәмгыятенең социаль үсеше һәм совет конфессиональ сәясәте буенча беренчел чыганак булып санала ала. Эчтәлек күрсәткәнчә, истәлекләр китабы гади көндәлек язмалар гына түгел, ә 1920 еллар башындагы татар җәмгыятенең сәяси, дини һәм иҗтимагый хәлен чагылдырган киң панорамалы чыганак булып тора. Анда авторның сәфәрләре, очрашулары, интеллектуаль бәхәсләре һәм шәхси кичерешләре бербөтен тарихи тукыма хасил итә.

Әлеге кыйммәтле чыганакны, гарәп хәрефләре белән татар телендә кулдан язылган катлаулы текстлардан укып, аларны зур төгәллек һәм фәнни җаваплылык белән төрек теленә тәрҗемә иткән Өмәр Хакан әфәнденең хезмәте аерым рәхмәт сүзләренә лаек. Ул текстларны гади рәвештә генә күчереп бирми, ә аларны җентекләп эшкәртә, кирәкле аңлатмалар, тарихи һәм текстологик искәрмәләр белән баета, укучыга контекстны тулырак аңларга ярдәм итә. Боларның һәммәсе төрек галименең гарәп-фарсы-төрки телләр, дин гыйлеме һәм тарих өлкәсендәге тирән эрудициясен, ныклы фәнни хәзерлеген һәм киң карашлы тикшеренүче булуын ачык рәвештә күрсәтә.

Китап ахырында урын алган 45 (!) битлек бай индекс: исемнәр, географик атамалар, дини терминнар, тарихи вакыйгалар һәм төшенчәләрне колачлаган киң күрсәткеч булып, басманың фәнни дәрәҗәсе тагын да күтәрелә. Бу индекс тикшеренүчеләр өчен аеруча әһәмиятле: ул әсәр өстендә системалы рәвештә эшләргә, конкрет мәсьәләләрне тиз табарга, текст эчендәге бәйләнешләрне ачыкларга мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, Өмәр Хакан Өзалп башкарган хезмәт – тәрҗемә генә түгел, ә тулы канлы фәнни-тәнкыйди басма / нәшер үрнәге. Татар дини-фикри мирасын киң төрки укучыга җиткерү юнәлешендәге бу тырышлыклары өчен галимгә ихлас рәхмәт белдерү бик тә урынлы булыр. 2025 ел башында сатуга чыккан бу китап әлегә татар галимнәре арасында киң әйләнешкә кермәде, бу язма аны таныту максатыннан әзерләнде.

**Әдәбият**

1. Bolşevik Rejimde Bir Tatar Şeyhülislâmı: Alimcan Barudi'nin Hatıraları (1920–1921). Tatarca yazma aslından Türkiye Türkçesi'ne aktaran Ömer Hakan Özalp. Istanbul: İşaret Yayınları, 2024. 717 s.

2. Sultan Abdülhamid'in Sarayında: Bir Tatar Müderrisin İstanbul, Bursa ve Surre Alayı le Hac Hatıraları: Nurali bin Hasan. Arapçadan tercüme: Ömer Hakan Özalp. İstanbul, İşaret yay. 2021. 466 s.

***Сибгатуллина Әлфинә Таһир кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Сибгатуллина Альфина Тагировна,***
*доктор филологических наук, ведущий научный сотрудник*
*Института востоковедения Российской Академии наук*

*alfina2003@yandex.ru*